КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 19 май г.Казань № 608

Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплау максатларында биналар һәм бүлмәләрне төзү һәм төзекләндерү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән күчемсез мөлкәт объектларын арендага бирүче юридик затларга 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Карарга теркәлгән Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплау максатларында биналар һәм бүлмәләрне төзү һәм төзекләндерү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән күчемсез мөлкәт объектларын арендага бирүче юридик затларга 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 17 апрель, 482 нче
карары белән расланды

Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплау максатларында биналар һәм бүлмәләрне төзү һәм төзекләндерү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән күчемсез мөлкәт объектларын арендага бирүче юридик затларга 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибе

1. Әлеге Тәртип кунакханә хезмәтләре күрсәтү яисә халык куллану товарларын һәм азык-төлек товарларын саклау буенча махсус саклау шартлары таләп ителми торган хезмәт күрсәтүләр һәм биналар һәм бүлмәләр төзү һәм реконструкцияләү буенча инвестицион проектны гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән ахыргы кулланучыга җибәрүгә аларны комплектацияләү хезмәтләре күрсәтү өчен күрсәтелгән күчемсез мөлкәт объектларына карата оешмалар мөлкәтенә салым 2021 елда түләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплау максатларында арендага күчемсез милек объектларын бирүче юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләрдән тыш) 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр (алга таба - субсидия) бирү механизмын билгели.

2. Субсидия бирү әлеге Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатларга бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бюджет акчаларының баш бүлүчесенә - Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына (алга таба - Министрлык) җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

Субсидияләр турында белешмә, тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы (тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы) кабул ителгән көннән соң килә торган 15 нче эш көненнән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталындагы «Бюджет» бүлегендә Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә урнаштырыла.

3. Бу Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр:

Министрлык – юридик затларга кунакханә хезмәтләре күрсәтү яисә халык куллану товарларын һәм азык-төлек товарларын саклау буенча махсус саклау шартлары таләп ителми торган хезмәт күрсәтүләр һәм биналар һәм бүлмәләр төзү һәм реконструкцияләү буенча инвестицион проектны гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән ахыргы кулланучыга җибәрүгә аларны комплектацияләү хезмәтләре күрсәтүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү механизмын гамәлгә ашыру өчен җаваплы Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы;

заявка - кәгазьдә рәсмиләштерелгән документлар, әлеге Тәртип таләпләре нигезендә сайлап алуда катнашу өчен тапшырыла торган документлар;

сайлап алуда катнашучылар - кунакханә хезмәтләре күрсәтүче яисә халык куллану товарларын һәм азык-төлек товарларын саклау буенча махсус саклау шартлары таләп ителми торган хезмәт күрсәтүләр һәм биналар һәм бүлмәләр төзү һәм реконструкцияләү буенча инвестицион проектны гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән ахыргы кулланучыга җибәрүгә аларны комплектацияләү хезмәтләре күрсәтүче, Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли торган, дәүләт (муниципаль) учреждениеләре булмаган, Министрлыкка заявка тапшырган юридик затлар;

субсидия алучы - сайлап алуда җиңүче дип танылган сайлап алуда катнашучы;

килешү - Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган бертип форма нигезендә субсидия бирү турында карар кабул ителгән субсидия алучы арасында төзелә торган Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү турында килешү.

Әлеге Тәртиптә кулланыла торган башка төшенчәләр һәм терминнар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

4. Сайлап алуны үткәрү турында белдерү, заявкалар бирелә башлаган датага кадәрге бер эш көненнән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе бюджет системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге бердәм порталында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла, түбәндәгеләрне күрсәтеп:

сайлап алуны үткәрү срокларын;

заявкалар бирелә башлау яки кабул итүне тәмамлау датасын (ул сайлап алуны үткәрү турында белдерү урнаштырылган көннән соң килә торган 10 календарь көннән иртәрәк була алмый);

Министрлыкның исемен, урнашу урынын, почта адресын, электрон почта адресын;

бу Тәртипнең 19 пункты нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсен;

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуны үткәрү тәэмин итела торган домен исемен, һәм (яки) челтәр адресын, һәм (яки) сайт битләре күрсәткечләрен;

әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктлары нигезендә сайлап алуда катнашучыларга карата критерийлар һәм таләпләр һәм әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә әлеге критерийларга һәм таләпләргә туры килүен раслау өчен тапшырыла торган документлар исемлеге;

заявкалар бирү тәртибен һәм бу Тәртипнең 7 пунктының икенче абзацы нигезендә бирелә торган заявкалар формасына һәм эчтәлегенә карата куела торган таләпләрне;

заявкаларны кире алу тәртибен, заявкаларны кире кайтару (шул исәптән заявкаларны кире кайтару өчен нигезләрне билгели торган) тәртибен, заявкага үзгәрешләр кертү тәртибен;

әлеге Тәртипнең 9 - 13 пунктлары нигезендә гаризаларны карап тикшерү кагыйдәләрен;

сайлап алуда катнашучыларга сайлап алуны үткәрү турындагы белдерү нигезләмәләренә аңлатмалар бирү тәртибен, мондый аңлатмалар бирү срогы башлану һәм тәмамлану датасын;

сайлап алуда җиңүче тарафыннан килешүгә имза куелырга тиешле срокларны;
сайлап алуда җиңүчене килешү төзүдән баш тарткан дип тану шартларын;
сайлап алуда җиңүче билгеләнгән көннән соң килә торган 14 календарь көннән дә соңга калмыйча, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында һәм Министрлыкның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында сайлап алу нәтиҗәләрен урнаштыру датасын.

Сайлап алу сайлап алуда катнашучының әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүеннән, шулай ук заявкалар керүнең чиратлылыгыннан чыгып, тәкъдимнәр соратып алу юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Сайлап алуда катнашучы түбәндәге сайлап алу критерийларына туры килергә тиеш:

Татарстан Республикасы территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыра һәм Татарстан Республикасы бюджетына салымнар түли;

инвестицияләр күләме 2 млрд. сумнан да ким булмаган биналарны һәм бүлмәләрне төзү һәм реконструкцияләү буенча сайлап алуда катнашучының инвестиция проекты 2020 - 2022 елларга Татарстан Республикасы Инвестиция меморандумы тарафыннан билгеләнгән Татарстан Республикасы инвестиция сәясәтенең өстенлекле юнәлешләренә туры килә торган 2021 елга Татарстан Республикасының өстенлекле инвестиция проектлары исемлегенә кертелде;

сайлап алуда катнашучы әлеге пунктның өченче абзацында күрсәтелгән биналарны һәм бүлмәләрне төзү һәм реконструкцияләү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән күчемсез милек объектын халык куллану һәм азык-төлек товарларын саклау буенча хезмәт күрсәтүче, махсус саклау шартлары таләп ителми торган хезмәтләр күрсәтү һәм аларны комплектацияләү буенча ахыргы кулланучыга җибәрү хезмәте күрсәтүче оешмаларга арендага тапшырды.

6. Заявка бирү аена кадәрге айның 1 числосына сайлап алуда катнашучы туры килергә тиешле таләпләр:

салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмау;

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлары, шулай ук Татарстан Республикасы каршында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмау;

үзгәртеп оештыру (сайлап алуда катнашучы булган юридик затка кушу, башка юридик зат рәвешендә үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмау, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәү, сайлап алуда катнашучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмау;

дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкче, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы зат яки сайлап алуда катнашучының баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмау;

чит ил, шул исәптән теркәлү урыны Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган, Россия Федерациясендә активларга арадаш (офшор) ия булу өчен файдаланыла торган дәүләтләр һәм территорияләр (алга таба – офшор компанияләре) исемлегенә кертелгән дәүләт яки территория булган юридик зат, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмаска тиеш. Офшор компанияләренең Россия юридик затлары капиталында катнашу өлешен исәпләп чыгарганда акцияләре Россия Федерациясендәге оештырылган торгларда әйләнештә йөри торган гавами (шул исәптән халыкара компания статусы булган) акционерлык җәмгыятьләре капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры һәм (яки) турыдан-туры булмаган катнашуы, шулай ук мондый офшор компанияләренең башка Россия юридик затлары капиталында әлеге гавами акционерлык җәмгыятьләре капиталында катнашып тормышка ашырылган турыдан-туры булмаган катнашуы исәпкә алынмый;

бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен башка норматив хокукый актлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алучы булмау;

экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә тормый.

7. Сайлап алуда катнашу өчен сайлап алуда катнашучы сайлап алуны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән срокта заявка бирә.

Сайлап алуда катнашучы Министрлыкка түләү реквизитлары һәм почта адресы күрсәтелгән, шул исәптән сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында күрсәтелгән критерийларга һәм таләпләргә туры килүе турында мәгълүмат бирелгән, түбәндәге документлар теркәлгән, Министрлык боерыгы белән расланган формада язылган заявка тапшыра:

«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә сайлап алуда катнашучы турында, сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелә торган заявка һәм сайлап алуга бәйле сайлап алуда катнашучы турында башка мәгълүматны бастыруга (урнаштыруга) ризалык;

заявка бирелгән айга кадәрге айның 1енче көненә карата Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан алынган, билгеләнгән тәртиптә расланган өземтә (сайлап алуда катнашучы тарафыннан мондый документ тапшырылмаган очракта, Министрлык аны мөстәкыйль соратып ала);

кунакханә хезмәтләре күрсәтү яисә халык куллану товарларын һәм азык-төлек товарларын саклау буенча махсус саклау шартлары таләп ителми торган хезмәт күрсәтүләр һәм биналар һәм бүлмәләр төзү һәм реконструкцияләү буенча инвестицион проектны гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән ахыргы кулланучыга җибәрүгә аларны комплектацияләү хезмәтләре күрсәтү өчен оешмаларга арендага бирелгән күчемсез милек объекты (алга таба - күчемсез милек объекты) турында сайлап алуда катнашучы җитәкче һәм баш хисапчысы кул куйган белешмә, мәйданын күрсәтеп;

заявка бирелгән айга кадәрге айның 1енче көненә карата сайлап алуда катнашучының салымнар һәм җыемнар турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмавын раслый торган салым органының белешмә кәгазе (сайлап алучы тарафыннан мондый документ бирелмәгән очракта Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

заявка бирелгән айга кадәрге айның 1енче көненә карата дисквалификацияләнгән затлар реестрыннан сайлап алуда катнашучының дисквалификацияләнгән затлар реестрында дисквалификацияләнгән җитәкчесе, коллегиаль башкарма орган әгъзалары, бердәм башкарма орган функцияләрен башкаручы заты яки баш бухгалтеры турында мәгълүматлар булмавын раслый торган өземтә (сайлап алучы тарафыннан мондый документ бирелмәгән очракта Министрлык аны мөстәкыйль рәвештә соратып ала);

субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен (шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгәннәрне) Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтару буенча вакытында түләнмәгән бурычлар, шулай ук Татарстан Республикасы алдында акча йөкләмәләре буенча вакытында түләнмәгән (җайга салынмаган) башка бурычлары булмавы турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 1 пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан акча алмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының офшор компаниясе, шулай ук устав (җыелма) капиталында офшор компанияләренең турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган (өченче затлар аша) катнашу өлеше барысы бергә 25 проценттан арткан Россия юридик заты (әгәр Россия Федерациясе законында башкасы каралмаса) булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазен;

Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган форма буенча 2021 елга сайлап алуда катнашучының оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым декларациясе, Россия Федерациясе Салым кодексында билгеләнгән срокларда салым декларациясе телекоммуникация элемтә каналлары буенча җибәрелүен һәм салым органы тарафыннан алынуын раслый торган квитанция һәм хәбәрнамә;

әлеге Тәртипкә кушымтадагы форма буенча 2021 елда оешмалар мөлкәтенә салым түләнгән сайлап алуда катнашучының күчемсез милек объекты турында мәгълүмат;

2021 елга оешмалар мөлкәтенә салым түләүне раслый торган түләү документларының күчермәләре;

күчемсез милек объектын арендалау шартнамәләренең күчермәләре;

сайлап алуда катнашучының үзгәртеп оештыру (башка юридик затны сайлап алуда катнашучы юридик затка кушу формасында үзгәртеп оештырудан тыш), бетерү процессында булмавы, аңа карата банкротлык процедурасы билгеләнмәве, сайлап алуда катнашучы эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә

туктатылмавы турында сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе;

сайлап алуда катнашучының экстремистик эшчәнлеккә яки террорчылыкка катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә яисә массакүләм юк итү коралын таратуга катнашы булу турында мәгълүмат бирелгән оешмалар һәм физик затлар исемлегендә булмавын раслый торган, сайлап алуда катнашучының җитәкчесе һәм баш бухгалтеры (булганда) тарафыннан кул куелган белешмә кәгазе.

Заявка тегелгән, номерланган, вәкаләтле зат тарафыннан кул куелган һәм аңа сайлап алуда катнашучы мөһере (булганда) сугылган булырга тиеш.

Министрлыкка тапшырыла торган мәгълүматларның дөрес булмавы, шулай ук сайлап алуда катнашучының документлары ялганлап ясалуы өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап бирә.

8. Сайлап алуда катнашучы сайлап алу вакыты чыкканчы заявканы теләсә кайсы вакытта кире алырга хокуклы.

9. Министрлык әлеге Тәртипнең 7 пунктында каралган заявкаларны һәм документларны кабул итә һәм, заявкалар кергән датаны һәм вакытны күрсәтеп, алар кергән көннән алып бер көн эчендә заявкаларны теркәү журналында терки. Заявкага, аның Министрлыкка керү чиратына карап, тәртип номеры бирелә.

Заявкалар кабул итү срогы тәмамланганнан соң ике эш көненнән артмаган срокта Министрлык заявкаларны Министрлыкка керү чиратлылыгы тәртибендә әлеге Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында каралган сайлап алу критерийларына һәм таләпләренә туры килү тәртибендә тикшерә, шулай ук әлеге Тәртипнең 7 пункты нигезендә заявка составында тапшырылган документларны тикшерә.

10. Заявкаларны карап тикшерү стадиясендә заявканы кабул итмәү өчен нигезләр:

сайлап алуда катнашучының бу Тәртипнең 5 һәм 6 пунктларында билгеләнгән критерийларга һәм таләпләргә туры килмәве;

сайлап алу турында игъланда билгеләнгән сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән гаризаларның һәм документларның сайлап алуда катнашучыларның гаризаларына карата таләпләргә туры килмәве;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның, шул исәптән юридик зат урнашу урыны һәм адресы турындагы мәгълүматның дөрес булмавы;

сайлап алуда катнашучы тарафыннан заявканың аны бирү өчен билгеләнгән датадан һәм (яки) вакыттан соң бирелүе;

11. Сайлап алуны уздыру нәтиҗәләре буенча Министрлык сайлап алуның җиңүчесен (җиңүчеләрен) билгели һәм әлеге Тәртипнең 9 пунктының икенче абзацында күрсәтелгән срок тәмамланган көннән алып өч эш көненнән артмаган срокта субсидия бирү турында йә субсидия бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

Министрлык тарафыннан Министрлык боерыгы белән расланган рәвештә сайлап алу нәтиҗәләре турында (сайлап алу узу яки заявканы кире кагу турында) реестр төзелә.

12. Субсидия алучыга субсидия бирүдән баш тарту өчен нигезләр:

субсидия алучы тарафыннан бирелгән документлар бу Тәртипнең 7 пункты нигезендә билгеләнгән таләпләргә туры килмәү яки әлеге документлар тапшырылмау (тулы күләмдә тапшырылмау);

субсидия алучы тарафыннан бирелгән мәгълүматның дөрес булмау фактын билгеләү.

13. Кабул ителгән карарның нәтиҗәләре турында хәбәрнамә сайлап алуда катнашучыга Министрлык тарафыннан язма рәвештә тиешле карар кабул ителгән көннән алып биш эш көне эчендә электрон почта яисә заявкада күрсәтелгән почта адресы аша җибәрелә.

14. Министрлык әлеге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән карарларны кабул итү нәтиҗәләре буенча өч эш көне эчендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында түбәндәге белешмәләрне үз эченә алган сайлау нәтиҗәләре турында мәгълүмат урнаштыруны тәэмин итә:

заявкаларны карап тикшерүне үткәрү датасы, вакыты һәм урыны;

заявкалары карап тикшерелгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат;

заявкалары кабул ителмәгән сайлап алуда катнашучылар турында мәгълүмат (аларны кабул итүдән баш тарту сәбәпләрен, шул исәптән сайлап алуны үткәрү турындагы белдерүнең мондый заявкалар туры килми торган нигезләмәләрен күрсәтеп);

килешү төзелә торган субсидия алучыларның исемнәре һәм аларга бирелә торган субсидиянең күләме.

15. Субсидия күләме (С) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$C = B_1 \times (N_1 - 0{,}1\%),$$

монда:

$B_1$ – әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә мәгълүмат нигезендә билгеләнә торган, 2021 елда оешмалар мөлкәтенә салым түләнгән сайлап алуда катнашучының күчемсез мөлкәт объектының уртача еллык бәясе;

$N_1$ – «Оешмалар мөлкәтенә салым турында» 2003 елның 28 ноябрендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 2 статьясындагы 1 өлеше нигезендә һәм 2021 елда гамәлдә булган сайлап алуда катнашучы оешмалар мөлкәтенә салым буенча салым ставкасы

16. Субсидия бирелә торган чыгымнарның юнәлешләре булып 2021 елда күчемсез милек объектына карата оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле субсидия алучы тарафыннан фактта тотылган чыгымнар (документаль расланган) тора.

17. Субсидия бирү килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

Килешү Министрлык белән субсидия алучы арасында Министрлык субсидия бирү турында карар кабул иткән көннән алып эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә төзелә.

Килешүдә түбәндәгеләр карала: субсидия күләме; субсидия бирү нәтиҗәсенең төгәлләнү датасы һәм ахыргы мәгънәсе (нәтиҗәләрнең конкрет микъдари

характеристикасы); субсидия бирелә торган чыгымнар юнәлешләре; субсидияне күчерү тәртибе; субсидия алучының Министрлык тарафыннан субсидия бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешен тикшерүгә (шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә) һәм дәүләт финанс контроле органнары тарафыннан Россия Федерациясе Бюджет кодексының $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерүне гамәлгә ашыруга ризалыгы; субсидияне кире кайтару очраклары; субсидия алучы тарафыннан бу Тәртип нигезендә субсидия бирү нәтиҗәсе мәгънәләренә ирешү турында хисап бирү тәртибе һәм сроклары, субсидия алучы тарафыннан өстәмә хисаплылык бирү сроклары һәм формалары (кирәк булганда); бу Тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән, элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары Министрлыкка киметелгән очракта, субсидияне килешүдә билгеләнгән күләмдә бирү мөмкин булмавына китерә торган килешүнең яңа шартларын килештерү турында яки яңа шартлар буенча килешүгә ирешеп булмаганда килешүне өзү турында шарт.»;

Әгәр субсидия алучы килешүгә бу пунктның икенче абзацында күрсәтелгән срокта кул куймаган булса, ул килешү төзүдән баш тарткан дип санала.

Кирәк булганда Министрлык белән субсидия алучы Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бертип форма нигезендә килешүгә өстәмә килешү, шул исәптән килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.

18. Субсидия Россия Федерациясе Үзәк банкы яисә кредит оешмалары учреждениесендә, башкарма комитет тарафыннан субсидия бирү турында карар кабул ителгән көннең иртәгесеннән дә соңга калмыйча, субсидия алучы тарафыннан ачылган исәп-хисап яки корреспондент счетына күчерә.

19. Субсидия бирү нәтиҗәсе - күчемсез милек объекты мәйданының зурлыгы (субсидия бирү нәтиҗәсенең мәгънәсе килешүдә билгеләнә.

20. Субсидия алучы, субсидия бирелгән елдан соң килә торган елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча, Министрлыкка Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән килешүнең бертип формасында билгеләнгән форма буенча субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап тапшыра.

21. Министрлык субсидия алучының субсидия бирү тәртибен һәм шартларын, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлешендә үтәвен тикшерүне гамәлгә ашыра. Дәүләт финанс контроле органнары Россия Федерациясе Бюджет кодексыныңhttps://login.consultant.ru/link/?req=doc&base=LAW&n=402282&date=30.01.2023&dst=3704&field=134 $268^1$ һәм $269^2$ статьялары нигезендә тикшерү үткәрә.

Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешүне мониторинглау, килешүдә билгеләнгән субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә ирешүдән һәм субсидия бирү нәтиҗәсен алу буенча тиешле чараны тәгәлләү факты чагылдырыла торган вакыйгалардан (контроль нокта) чыгып, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм формалар буенча үткәрелә.

22. Бирелгән субсидияләр субсидияләр субсидияләр алучы тарафыннан субсидия биргәндә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, шул исәптән Министрлык һәм дәүләт финанс контроле органы үткәргән тикшерүләр фактлары буенча, шулай ук субсидия бирү нәтиҗәләре күрсәткечләренә җитмәгән очракта, Министрлыкның тиешле таләбе алынган көннән алып 60 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджеты керемнә кире кайтарылырга тиеш.

23. Субсидия алучы тарафыннан әлеге Тәртипнең 22 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару сроклары бозылганда, Министрлык субсидияне кире кайтару срогы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләтү буенча чаралар күрә.

24. Субсидия алучылар тарафыннан Министрлыкка тапшырыла торган мәгълүматның һәм документларның дөреслеге өчен җаваплылык субсидия алучы җитәкчесенә йөкләнә.

25. Субсидияне файдалануны тикшерүдә тоту Министрлык тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Оешмалар мөлкәтенә салым түләүгә бәйле чыгымнар өлешен каплау максатларында биналар һәм бүлмәләрне төзү һәм төзекләндерү буенча инвестиция проектын гамәлгә ашыру кысаларында төзелгән күчемсез мөлкәт объектларын арендага бирүче юридик затларга 2023 елда Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә кушымта

Форма

_____________ хезмәтләр күрсәтү өчен оешмаларга арендага тапшырылган ___________ ел өчен оешмалар мөлкәтенә салым түләгән юридик затның күчемсез милек объектлары турында мәгълүмат

| Т/с | ИФНС, ОКТМО буенча код, объект | Инвентар номеры | Файдалануга тапшыру датасы | Салым чорына күчемсез мөлкәт объектының уртача еллык бәясен исәпләү өчен белешмәләр - салым салу объекты дип танылa торган төп чараларның калган бәясе, сум | | | | | | | | | | | | | Салым чорында уртача еллык бәя, сум | Салым ставкасы, % | Салым чоры өчен салымның исәпләп чыгарылган суммасы, сум |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 | 15 | 16 | 17 | 18 | 19 | 20 |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Юридик зат җитәкчесе
(вәкаләтле зат) ____________________ _____________________________
(имза) (имзаны таркатып язу)

Юридик затның баш хисапчысы ____________________ _____________________________
(имза) (имзаны таркатып язу)

20__ ел «___» ________

_______________________________________